ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
БАВЛИНСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
БАУЛЫ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

09.04.2019 Баулы шәһәре №93

Баулы муниципаль районы
Башкарма комитетының кайбер
карарларын гамәлдән чыгару турында

Россия Федерациясе Хөкүмәтенең 2016 елның 6 сентябрендә кабул ителгән 887нче номерлы «Юридик затларга (дәүләт (муниципаль) учреждениеләренә субсидияләрдән тыш), индивидуаль эшкуарларга, шулай ук товарлар җитештерүче, эшләр башкаручы, хезмәт күрсәтүче физик затларга субсидия бирүне җайга салучы норматив хокукый актларга, муниципаль хокукый актларга карата гомуми таләпләр турында» карары (2018 елның 20 ноябрендәге редакциядә) нигезендә Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты

КАРАР ИТӘ:

1. Гамәлдән чыгарырга:

- Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитетының «Баулы муниципаль районында шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга саву аппаратлары сатып алуга чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү тәртибен раслау турында» 2018 елның 14 ноябрендә кабул ителгән 426нчы номерлы карарын;

- «Шәхси ярдәмче хуҗалык алып баручы гражданнарга 2018-2019 елда Баулы муниципаль районы территориясендә сөтчелек юнәлешендә мини-фермалар төзү чыгымнарының бер өлешен каплау өчен субсидияләр бирү комиссиясе төзү турындагы нигезләмәне раслау хакында» Татарстан Республикасы Баулы муниципаль районы Башкарма комитеты карарын.

2. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемә алам.

Җитәкче И.И. Гозәеров